**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Байлангар авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2021 елның 11 ноябре** **N29**

**«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Нормабаш авылы, Вахит урамы, 18 нче адрес буенча урнашкан Нормабаш авылы ял паркы янынида үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Нормабаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Нормабаш авылының Х. Такташ урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Нормабаш авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Нормабаш авылының урам юл челтәрен карап тоту; (юлларны кардан чистарту, җәен авыл территориясен чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Вахитов урамы буенча урнашкан Нормабаш авылы су башнясын ремонтлау (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү);
- Вахитов урамы буенча Нормабаш авылы суүткәргечен ремонтлау (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү);
- Нормабаш авылында Вахит урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Байлангар авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы И. Ф.Каримуллин